**СОВЕТ НОВОШЕШМИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

423190, с. Новошешминск, ул. Советская, 80
тел.: (84348) 2-31-00, факс: (8-4348) 2-20-22

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЯҢА ЧИШМӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ**

423190,Яңа Чишмә авылы, Совет урамы, 80
тел.: (8-4348) 2-31-00, факс: (84348) 2-20-22

тел.: (8-84348) 2-31-00, факс: (8-84348) 2-20-22, chishma@tatar.ru

Бишенче чакырылыш Татарстан Республикасы
Яңа Чишмә муниципаль районы Советы
КАРАРЫ

2026 елның 3 апреленнән № 8-48

**Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районында муниципаль-хезмәт турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2023 елның 6 сентябрендәге 36-296 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында**

2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» Федераль закон, Россия Федерациясе Президентының 2025 елның 31 декабрендәге 1009 номерлы Указы, муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы Кодексы, «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советы

КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советының 2023 елның 6 сентябрендәге 36-296 номерлы карары белән (Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советының 2024 елның 27 мартындагы 43-335 номерлы, 2024 елның 23 октябрендәге 49-381 номерлы, 2025 елның 15 октябрендәге 2-11 номерлы карарлары редакциясендә) расланган Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районында муниципаль хезмәт турында нигезләмәгә (алга таба - Нигезләмә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Нигезләмәнең 14 статьясында:

а) 1 нче өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Муниципаль хезмәт вазыйфасын биләүне дәгъвалаучы граждан, муниципаль хезмәткәр әлеге Федераль законда билгеләнгән очракларда яллаучы вәкиленә (эш бирүчегә) керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында «Коррупциягә каршы көрәш турында» Федераль законда каралган белешмәләрне тапшыралар. Күрсәтелгән белешмәләр Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре тарафыннан «Коррупциягә каршы көрәш турында» Федераль законда каралган керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр тапшыру өчен билгеләнгән тәртиптә, срокларда һәм форма буенча тапшырыла.»;

б) 2 нче өлешне түбәндәге редакциядә бирергә:

«2. Муниципаль хезмәт урынын биләгән муниципаль хезмәткәр, тиешле исемлеккә кертелгән, 2012 елның 3 декабрендәге 230-ФЗ номерлы «Дәүләт вазифаларын биләгән затларның һәм башка затларның керемнәренә туры килүче чыгымнарны контрольдә тоту турында» Федераль законда (алга таба – «Дәүләт вазыйфаларын биләүче затларның һәм башка затларның чыгымнарының аларның керемнәренә туры килүен тикшереп тору турында» Федераль закон) каралган чыгымнар турында мәгълүматларны, Россия

Федерациясе субъектларының дәүләт граждан хезмәткәрләре тарафыннан шундый мәгълүматларны тапшыру тәртибе һәм формасы буенча тапшырырга бурычлы.»;

в) 3 нче өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Муниципаль хезмәткәрнең, аның хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәренә туры килүен тикшереп тору «Коррупциягә каршы көрәш турында» Федераль законда һәм«Дәүләт вазифаларын биләгән затларның һәм башка затларның керемнәренә туры килүче чыгымнарны контрольдә тоту турында» Федераль законда, Россия Федерациясе Президентының норматив хокукый актларында, муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы Кодексында, Татарстан Республикасы Башлыгының (Рәисенең) норматив хокукый актларында, муниципаль хокукый актларда каралган тәртиптә гамәлгә ашырыла.»;

г) 4 нче өлештә «керемнәр, чыгымнар, милек һәм милек характерындагы йөкләмәләр турында» сүзләрен төшереп калдырырга;

д) 5 нче өлештә «керемнәр, чыгымнар, милек һәм милек характерындагы йөкләмәләр турында мәгълүматлар» сүзләрен «муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан әлеге статья нигезендә тәкъдим ителә торган мәгълүматлар» сүзләренә алыштырырга;

е) 6 нчы өлештә «керемнәр, чыгымнар, милек һәм милек характерындагы йөкләмәләр турында мәгълүматлар» сүзләрен «муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан әлеге статья нигезендә тәкъдим ителә торган мәгълүматлар» сүзләренә алыштырырга;

ж) 7 нче өлештәге «керемнәр, чыгымнар, милек һәм милек характерындагы йөкләмәләр, шулай ук хатынының (ирењнең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, милеге һәм милек характерындагы йөкләмәләре турында мәгълүматлар» сүзләрен «Коррупциягә каршы көрәш турында» Федераль законда каралган керемнәр, милек һәм милек характерындагы йөкләмәләр турында мәгълүматлар һәм «Дәүләт вазыйфаларын биләүче затларның һәм башка затларның чыгымнарының аларның керемнәренә туры килүен тикшереп тору турында» Федераль законда каралган чыгымнар турында мәгълүматлар,» сүзләренә алыштырырга;

з) 9 нчы өлештәге «273-ФЗ номерлы закон һәм Россия Федерациясенең башка норматив-хокукый актлары, Татарстан Республикасы югары вазыйфаи затының норматив хокукый актларында билгеләнә торган тәртиптә гамәлгә ашырыла» сүзләрен «Коррупциягә каршы көрәш турында» Федераль закон һәм Россия Федерациясенең башка норматив-хокукый актлары, Татарстан Республикасы Башлыгының (Рәисенең) норматив хокукый актларында билгеләнә торган тәртиптә гамәлгә ашырыла.» сүзләренә алыштырырга;

и) 10 нчы өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«10. Контракт буенча Башкарма комитеты Җитәкчесе вазыйфасын биләүгә дәгъва кылучы гражданнар әлеге статьяның 1 нче өлешендә күрсәтелгән мәгълүматларны, мондый вазыйфаны биләүче зат әлеге статьяның 1 нче һәм 2 нче өлешләрендә күрсәтелгән мәгълүматларны Татарстан Республикасы законы белән билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы Башлыгына (Рәисенә) тапшыралар.»;

к) 11 нче өлешне үз көчен югалткан дип танырга;

1.2. Нигезләмәнең 16 статьясындагы 4 нче өлештәге 10 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«10) «Коррупциягә каршы көрәш турында» Федераль закон белән каралган керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында мәгълүмат;».

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы»нда https://pravo.tatarstan.ru, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталында Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында https://novosheshminsk.tatarstan.ru бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советының законлылык, хокук тәртибе һәм җирлекләрнең вәкиллекле органнары белән үзара хезмәттәшлек буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

4. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көннән гамәлгә керә дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Яңа Чишмә муниципаль районы Башлыгы Е.А. Тарнавский